Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

18 май 2020 года № 652

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы йомгаклары буенча бирелгән акчалардан территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисен һәм активын бүләкләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 июнендәге 901 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 01 июнендәге 391 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 03 апрелендәге 720-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы йомгаклары буенча бирелгән акчалардан территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисен һәм активын бүләкләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 июнендәге 901 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 июлендәге 1308 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 964-р номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 03 апрелендәге 720-р номерлы күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2) Карарның 1 пунктында «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88 номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акчалар исәбеннән» сүзләрен «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акчалар исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 нче кушымтаның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 964-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 03 апрелендәге 720-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 1 нче кушымтаның 2 пунктында «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88 номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган»

сүзләрен «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе т М.Н. Гирфанов